ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советы

422756, ТР Әтнә муниципаль районы,
Олы Мәңгәр авылы, Совет урамы, 8
тел. 34-6-25

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Большеменгерского сельского поселения
Атнинского муниципального района

422756, РТ, Атнинский муниципальный район
село Большой Менгер, улица Советская, 8
тел. 34-6-25

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советы**

КАРАР

“18” февраль 2022 ел № 40

**Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 октябрендәге 59 нчы номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы “Олы Мәңгәр авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә төзекләндерү Кагыйдәләре” нә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

1993 нче елның 14 маендагы 4979-1 номерлы "Ветеринария турында" гы Федераль законга, 2021 нче елның 11 нче июнендәге 170-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр керү сәбәпле, Әтнә районы прокуратурасының 2022 елның 15 февралендәге 02-08-02/Прдп81-22 номерлы протестын карап һәм тикшереп, Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 октябрендәге 59 нчы номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы “Олы Мәңгәр авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә төзекләндерү Кагыйдәләре” нә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче бүлекнең 58 нче абзацында «контроль» сүзен төшереп калдырырга;

1.2. 3 нче бүлектәге 3.11 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

1.3. 14 нче бүлекнең 14.15 пунктының 1 пунктчасында "терлекчелек продуктлары" сүзләрен "терлек продукциясе" сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 15 нче бүлекне үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб –адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә, (1.3 пункт 2023 нче елның 1 мартыннан үз көченә керә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы Әтнә
муниципаль районы Олы Мәңгәр
авыл җирлеге башлыгы: Ф.К.Тахавиев